**Башлангыч сыйныфларда " Тылсымлы тавышлар, хисләр һәм уйлар дуслыгы» әдәби-музыкаль кичә конспекты**

Максаты: сәнгать һәм аның кеше тормышында урыны турында белемнәрне формалаштыру, сәнгать тарихын өйрәнү, күзаллауларны киңәйтү һәм балаларда танып-белү кызыксынуын үстерү

Бурычлар: Балаларда сәнгатьнең төрле төрләре һәм аларның мәдәнияттә һәм тормышта уртаклыгы турында күзаллау формалаштыру.

Җиһазлар, ноутбуклар, композиторлар, рәссамнар портретлары, кәгазь, төсле карандашлар, сәхнә геройлары өчен костюмнар.

Чарада катнашучылар: башлангыч сыйныф укучылары, 4әр кешедән торган төркемнәргә бүленгәннәр һәм 5 сыйныф укучылары.

**Чараның барышы**
Укытучының кереш сүзе.

- Сәнгать дөньясы искиткеч.
Сәнгатьнең күп кенә төрләре арасында үзенчәлекле ,иң мөһим өч әйбер бар :әдәбият, музыка, сынлы сәнгать. Сүз, аваз, сурәт - алардан башка сәнгатьнең башка төрләре - спектакль дә, фильм да, концертның да булуы мөмкин түгел. **“Тылсымлы тавышлар, хисләр һәм уйлар дуслыгы» әдәби-музыкаль телдән** журнал битләрендә сезгә зур сәнгать дөньясы ачылачак.
Шулай итеп, беренче битне ачабыз.

II.Рәссам килә (5 сыйныф укучысы)
Минем сәнгать иң борынгы өч төп төрнең берсе. Кешеләр әле сөйли дә белмәгәннәр, ә сурәтләрне иҗат иткәннәр. Сынлы сәнгатьне рәссамнар тудыра. Дөньяны без барыбыз да бертөсле күрәбез , ә аны рәссам үзенчә күрә. Бар нәрсәне дә сурәтләргә була: предметлар, кешеләр, хайваннар дөньясын, һәм күренмәс хисләр - шатлык һәм хәсрәтне, дөреслек һәм ялганны, игелек һәм явызлык дөньясын.
-Укучылар, ә сез кайсы рәссамнарны беләсез? Берничә рәссамны атагыз әле. (Иван Айвазовский, Виктор Васнецов, Михаил Врубель, Исаак Левитан һ. б.)
Рәссамнар күп, алар төрлечә эшли, аларны төрлечә атыйлар. Рәссамнар пумала һәм буяулар белән эшли.
Балчык, пластилин, ташлардагы сурәтләрне скульпторлар иҗат итә.
- Балчык уенчыклар, савыт-саба, кошлар, җәнлекләр һәм кешеләр рәсемнәре белән шөгыльләнүче рәссамнар да бар.
Хәзер мин тылсымлы пумалам белән селтәнәм һәм сезне рәссамнарга әверелдерәм. (тылсымлы музыка уйный)
Һәр төркем рәсем ясарга тиеш. Нәрсә ясарга икәнлеген табышмакны чишкәннән соң белерсез.

**1 төркем.-**

Түгел югары, түбән,
түгел ерак һәм якын
Күктә кызган шар йөзә-
беләсезме җавабын.

(Кояш)

**2 төркем**.

Күңелемә шундый якын
Туган йортым, туган нигез.
Җай булуга кайтам тизрәк
Читтә торсын сихри диңгез

**3 төркем**.

Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә.

Өебезнең нуры ул, барыбыздан олы ул. **(Әби)**

Ул бик күпне күргән, сугышта да булган ул.

Йөзе нурлы айдай… Кем дисезме? Ул минем **(Бабай).**

Ул зирәк тә, шаян да, акыллы да, әйбәт тә!

Иң – иң батыр кеше ул, минем **(Әти)**, әлбәттә!

Мин аны бик сагындым, күңелем әрни, уйлый әллә ни.

Кем соң аны белми? Ул бит минем **(Әни)**

..Боларны бер сүз белән берләштерсәк нинди сүз килеп чыга

(Гаилә )

Рәсемнәр тактага эленә.

Укытучы: Укучылар, карагыз әле эшләрне берләштергәч нинди матур рәсем килеп чыкты. Сездә бу рәсемгә карагач нинди фикер туды?

III. ШИГЪРИ СӘХИФӘ.

Укытучы:

Шигырь язу өчен, иң беренче,
Ышандыру кирәк үзеңне.

Серләреңә хисләреңне кушып,
Язу кирәк уйлап сүзеңне.

Бер язасың, бер бозасың әле,
Гаҗәпләнмә бер дә син аңа.
Таш астында калса да бер шытым,
Барыбыр чыга, үзенә юл ала.

Кешеләрдән тик яхшылык эзлә,
Усал булганнарга бул түзем.
Оялырлык булма кеше алдында,
Туры булсын юлың, ак йөзең.

Тормыш матурлыгын, хәсрәтләрен
Кичерергә өйрән күңелдән.
Шул чагында челтер чишмә булып
Шигырь чыгар күңел түреңнән.

- Шигъры̣ят дөньяны яңача, сиңа кадәр беркем дә күрмәгән итеп күрә белүдән башлана. Ә моның өчен тирән хисле, үткен күзле, иркен фикер йөртә торган һәм дөньяга гашыйк кеше булырга кирәк. **Шигърият**– сүзләрнең гади сөйләмгә хас булмаган рәвештә ритмы, яңгырашы буенча билгеле бер тәртипкә китерелгән хәле. Сүзләрне шундый хәлгә китерүгә нигезләнгән нәфис әдәбиятның бер тармагы ул. .

Муза керә.
Борынгы заманнардан ук иҗат ителгән барлык әдәби әсәрләрне ике зур төркемгә бүләргә була: поэзия һәм проза. Аларны аерырга җиңел.
Поэзия-шигърият-шигырьләр язылган әсәр, ә проза (чәчмә әсәр) -калганы.
Шигырьләр иҗат итү-бик гади генә эш түгел.
Әлбәттә, һәр шигырьнең үз көе, үз ритмы. -Шигырь - тезмә формага салынган, сүзләр, иҗекләр ритм таләбенә ярашлы итеп урнаштырылган әдәби әсәр.
“Шигырьне язалармыни? Шигырь белән яшиләр... дөресрәге, ул үзе җаныңда бер изге зат булып яши. Аңа бернинди аерым вакыт та, махсус шартлар да кирәкми “ – дип язган Хәсән Туфан. Аның сүзләре белән килешмичә мөмкин түгел

Шигырьләр язучыларны шагыйрьләр дип атыйлар.
- Хәзер мин үземнең тылсымлы каләмем белән сихерләп сезне шагыйрьләргә әверелдерәм.
Укытучы:
Безнең арада да шигырь язып караучылар бар. Хәзер аларны тыңлап үтик

VI. «Яңгыравык җиде нота " битен ачабыз.Бу МУЗЫКАЛЬ БИТ.
Укытучы:

- Без  тавышлар белән тулы дөньяда яшибез. Без аларны урамда, транспортта, эштә, өйдә ишетәбез. Күп кенә авазлар белән безне табигать каршы ала: агач яфракларын җил кыштырдата., үлән арасында чикерткә чыркылдый, тукран  агач кәүсәсен шакылдата..

Скрипка ачкычы керә.

Скрипка ачкычы:
Җыр, моң... Шушы өч хәрефтән торган сүзләргә дөнья үзе сыйган кебек. Табигатьнең һәр күренешендә, һәр мизгелендә җыр бар! Безнең һәр күзәнәгебез җыр дигән сихри аһәңне үзенә сеңдереп, башкача тормыш белән яши башлый. Шуңа күрә без, кешеләр, җыр-моңга тартылабыз, аны бик яратабыз. Җыр-моңнан башка яшәү - түбәсез йортта торуга, тозсыз аш ашауга...

Бары да үтә,
Бары да онытыла.
Байлык, зурлык китә, югала.
Тик җыр үлми
Күчеп буыннарга
Киләчәктә яшәп җыр кала

- Беренче чорда музыка кешенең үз тавышы  башкаруында гына яңгыраган. Бу музыканы вокал дип атыйлар.
 Башта кешеләр « ярдәмчеләрдән» башка җырлаган. Аннары, кул чабып, аяклар белән тыпырдап «ярдәм итә» башлыйлар. Димәк борынгы заманда  кеше үзе үк музыка коралы булган  икән дип аңлыйбыз. Соңрак кына кешеләр агач кисәкләрен, яссы ташларны куллана башлаганнар - алар тавышларны күпкә ачыграк күрсәтә һәм төрле төсләргә күмәләр.

Алга таба музыкаль тавышны суган, камыш сабагыннан яки торбалы сөяктән алып була, дип тапканнар кешеләр.

Укытучы:
Бу уен кораллары бүгенге көндә дә үзләренең актуальлекләрен югалтмыйлар. Безнен авылдашыбыз Әлфрит абый Сәмигуллин безгә курайда матур көйләр бүләк итәр. (Әлфрит абый чыгышы.)

**Скрипка ачкычы:**
.
- Хәзер мин дирижер таякчыгын алам һәм сез җырчыларга әверелдерәм.
**“Балтачым” җыры**
Укытучы:
Ярый әле без очсыз-кырыйсыз җирдә ялгыз түгел. Күңелләрне юатырдай җырларыбыз бар. Күбесе күңелгә үтеп керердәй моңнар. Җыр-кешенең балачагыннан алып, соңгы минутына кадәр аерылмас юлдашы. Җыр яраткан кеше матурлыкны ярата. Ә матурлыкны яраткан кеше беркайчан да начарлык эшләми. Ул

мәрхәмәтле, ярдәмчел була. Җыр аның гомерлек юлдашына әверелә. Бу сүзләр озак еллар мәдәният өлкәсендә эшләп, бүгенге көндә лаеклы ялда булган авылдашыбыз Нурулла абый Дәүләтшинга бик тә туры килә. Аның иҗатының яңа гөрләп чәчәк аткан вакыты. Соңгы елларда ул үзе җырлар иҗат итә башлады. “Шеңшеңәрем “ җыры белән ул хәтта Казан сәхнәләрендә дә чыгыш ясады. Сүзне Нурулла абыйга бирик әле.
Сорау :Нурулла абый, соңгы вакытта икенче сулыш алган кебек булдыгыз. Бу сәләтегез ачылуга нәрсә этәргеч бирде?

. Халыкларның җаны ул-моң диләр,
Моң диләр дә, бездә җыр диләр.
Өзгәләсә,телсә бәгырьләрне-
Татар җыры энә шул диләр,-дип язган шагыйребез Г. Тукай.

Театр бите.
- Сынлы сәнгать, әдәбият, музыка - әлеге сәнгать төрләренең һәркайсы бик матур һәм кабатланмас. Һәм алар барысы да бергә театрда берләшә.
- Спектакль – театр әсәре пьеса текстыннан, режиссер, актер, рәссам һәм композиторның эшләреннән гыйбарәт.
- Театр-коллектив сәнгать,
спектакль-ул иҗат.

Петрушка керә.
- Исәнмесез, балалар һәм өлкәннәр.
- Минем исемем Петрушка. Мин бик күңелле герой, курчак театрының баш актеры.
- Беләсезме, театр кайчан һәм кайда барлыкка килде?
Ул Борынгы Грециядә күп гасырлар элек барлыкка килгән.
- Ә Русьтә иң популяр курчак театры – **балаган** иде.
Ярминкәдә аны мәйдан уртасында төзиләр, гирляндалар, элмә такталар белән бизиләр һәм тамаша уйныйлар.
- Мин сезне үзебезнең балалар театрына чакырам
. Әйдәгез, ярминкәне бизик һәм күңелле тамаша уйнатыйк. Татар халкының «Саламторхан " әкиятенә рәхим итегез

Нәтиҗә.
Укытучы
- Сәнгать дөньясы искиткеч. Ә аңа юл синең күңелеңдә, йөрәгеңдә башлана.
Үз күңелең өчен дөньяның гаҗәп матурлыгын ачарга,күрергә өйрәнегез

Татар моңсыз яши аламени
Татар күңеленә моң кирәк
Тальяныңны гына сызып җибәр
Дәррәү кушылыр аңа мең йөрәк.